| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского<br>поселения Менделеевского<br>муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге Советы |
|---|---|

| Р Е Ш Е Н И Е<br>18.12. 2023 ел | К А Р А Р<br>№103 |
|---|---|

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының 2023 елның 14 февралендәге 75 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 статьяның 17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 2.5 статьяның 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классны чин бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Бөрешле авыл җирлеге Советы рәисе Л.А. Смирнова